| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**31.08.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1719** |

«2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» программасын раслау турында

1996 елның 12 февралендәге «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2015 елның 27 августындагы пр-263 номерлы Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның III Республика форумы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләренең 3 пунктын үтәү йөзеннән һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» программасын әлеге карарга кушымтада каралганча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С.Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А.Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 31 августындагы
1719 номерлы карарына
кушымта

«2019-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасы Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2019-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказчы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 27 августындагы пр-263 номерлы Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның III Республика форумы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон. |
| Программаның максаты | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба - СЮ ККО) ярдәм күрсәтү һәм аларны үстерү. |
| Программаның бурычлары | 1) Зеленодольск муниципаль районының өлкән яшьтәге гражданнарының, инвалидларның, балаларның һәм яшьләрнең, шулай ук халыкның башка кимсенә торган төркемнәренең социаль статусын саклау максатыннан СЮ ККО нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру һәм тәэмин итү;<br>2) Зеленодольск муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бара торган СЮ ККО финанс, мөлкәти, мәгълүмати, консультация ярдәме күрсәтү;<br>3) Зеленодольск муниципаль районы территориясендә актуаль социаль проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән СЮ ККО проектларын, инновацион социаль хезмәтләрен гамәлгә ашыруга ярдәм;<br>4) районның иҗтимагый тормышында актив катнашучы гражданнар санын арттыруга ярдәм итү;<br>5) үсеп килүче буынга хәрби-патриотик тәрбия бирү;<br>6) милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә иҗтимагый инициативаларга ярдәм. |
| Программаны тормышка ашыру срогы | 2019-2020 еллар |
| Программаны ел һәм чыганакларга бүлеп финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 5000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән республика бюджеты акчалары - 2000 мең сум, муниципаль бюджет акчалары - 0 мең сум, бюджеттан тыш чаралар - 3000 мең сум. |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><td>Ел</td><td>Республика бюджеты</td><td>Муниципаль бюджет чаралары</td><td>Бюджеттан тыш чыганаклар</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1000</td><td>-</td><td>1500</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1000</td><td>-</td><td>1500</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2000</td><td></td><td>3000</td></tr>
</table>
Искәрмә:<br>Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Татарстан Республикасының чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль бюджетын формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программа максатларының һәм бурычларының көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td>
<td>Программаны тулы күләмдә гамәлгә ашыру 2020 ел ахырына түбәндәгеләрне ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>-ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар санын кимендә 14 берәмлеккә арттыру;<br>-Зеленодольск муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар санын 18 берәмлеккә арттыру. ЗМР СЮ ККО даими рәвештә актуаль реестрын алып бару;<br>- кимендә 8 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга финанс ярдәме күрсәтү;<br>-Зеленодольск муниципаль районында уздырылган иҗтимагый акцияләр һәм чаралар санын 25 берәмлеккә арттыру.</td>
</tr>
</table>

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларны тасвирлау һәм аның үсеш фаразы

Җирле үзидарә органнарының гражданнар фикерен һәм инициативаларын исәпкә алмыйча һәм фикер алышмыйча кабул ителгән карарлары, үз муниципаль район проблемаларына битарафлыгын арттырырга, хакимиятнең теләсә нинди карарларына һәм гамәлләренә ышанычсызлыгын арттырырга этәрә. Шуңа бәйле рәвештә, җирле үзидарәнең нәтиҗәле системасын үстерү халыкның үз тормыш сыйфатын яхшыртуда һәм муниципаль проблемаларны хәл итүдә кызыксындырмыйча катнаштырыудан башка мөмкин түгел.

Гражданлык җәмгыяте үз мәнфәгатьләренең һәм максатларының уртаклыгын аңлау нигезендә берләшүгә омтылган һәм үз проблемаларын гына түгел, ә башка кешеләрнең проблемаларын да хәл итә алган территориядә яшәүчеләрнең ирекле рәвештә үз-үзләрен табуы нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Гомумән алганда, «2019-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасы (алга таба - Программа) Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыруга һәм җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте белән муниципаль район халкы мәнфәгатьләрендә иҗтимагый берләшмәләрнең киң даирәсе белән диалог аша үзара хезмәттәшлеген үстерүгә юнәлдерелгән.

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә карый.

2018 елның 1 июленә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гражданнарның төрле категорияләре белән эш алып баручы һәм халыкка төрле социаль хезмәтләр күрсәтүче 123 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма теркәлгән һәм юридик зат статусына ия.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма халыкның актив һәм белемле өлешен берләштерә, гражданнарның мәнфәгатьләрен белдерүче буларак хезмәт итә. Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма шәһәр һәм район мәсьәләләрен хәл итүдә профессиональ катнаша, сыйфатлы социаль хезмәтләр күрсәтә ала. Алар халыкны социаль әһәмиятле булган мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итү өчен оештырырга әзер һәм булдыралар.

Зеленодольск муниципаль районында гражданлык җәмгыяте институтларын үстерү, муниципаль хакимиятләр һәм коммерцияле булмаган оешмаларның конструктив диалог юлларын эзләү максатларында 2008 елдан Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый палатасы эшли. Зеленодольск муниципаль районы советының 2014 елның 21 февралендәге 363 номерлы карары белән (2016 елның 16 августындагы 118 номерлы соңгы үзгәрешләр белән) расланган Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый палатасы турында нигезләмә белән Иҗтимагый совет эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре булып гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, муниципаль хокукый актлар проектларына җәмәгать экспертизасы үткәрү, муниципаль хакимият органнары эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру тора.

Әмма, күпме генә көч куелса да, Зеленодольск муниципаль районында гражданлык җәмгыяте институтларының барлыкка килү процессы шактый нәтиҗәле бара дип әйтеп булмый. Күп кенә иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеге ситуатив характерда һәм системалары юк.

Шуңа күрә программа чараларын гамәлгә ашыру кысаларында әлеге белешмәләр һәм яңа төзелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар социаль өлкәдә кайбер муниципаль бурычларны хәл итәргә ярдәм итәчәк. Мәсәлән: гражданнарны хокукый яклау, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне һәм ветераннарны социаль адаптацияләү,

гражданнарга социаль ярдәм системасын үстерү, милләтара хезмәттәшлеккә, шәхес үсешенә, ял оештыруга һәм ярдәмгә юнәлтелгән чаралар уздыру.

Шулай итеп, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар Зеленодольск муниципаль районының социаль-нәтиҗәле инфраструктурасын булдыруда ярдәм итәчәк.

Районның социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итү өчен көчләрне берләштерү максатларында үзара хокуклы субъектлар буларак җирле үзидарә органнары һәм коммерциягә карамаган оешмалар арасындагы мөнәсәбәтләр системасын булдыру зарурлыгы аеруча актуаль булып тора.

Программаны тормышка ашыру буенча эшчәнлекнең төп эчтәлеге - районның коммерциягә карамаган секторны формалаштыруга һәм аның нәтиҗәле эшләвенә ярдәм итә торган шартлар тудыру һәм аларга ярдәм итү. Уңай шартлар булганда, гражданлык активлыгын үстерү гражданлык җәмгыяте институтларының үз-үзен үстерүен тәэмин итәчәк, алар әкренләп район һәм аның халкы өчен актуаль булган бурычларны һәм проблемаларны хәл итү өчен үз җаваплылыгы өлкәсендә булдыра алачак.

Программа гражданлык җәмгыятен үстерүгә, гражданлык активлыгы һәм шәһәр халкының ирекле инициативалары өчен хокукый, икътисади һәм оештыру шартлары булдыруга юнәлдерелгән СЮ ККО ярдәм чаралары системасын билгели.

Программа «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 25 августындагы ПР-263 номерлы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның III Республика форумы йомгаклары буенча йөкләмәсе нигезендә төзелде. Программа районда социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү принципларын һәм рәвешләрен, шулай ук ККОга ярдәм күрсәтү буенча районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели. Әлеге программа СЮ ККО инициативаларына финанс, мөлкәт, мәгълүмати һәм консультатив ярдәм күрсәтүне күздә тота.

Моннан тыш, программа белән турыдан-туры яисә читләтеп стимуллаштыручы җирле үзидарә органнарын Зеленодольск муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итүнең төрле формаларын гамәлгә кертү каралган.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

Төп максат - Зеленодольск муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бара торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү һәм аларны үстерү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Зеленодольск муниципаль районы халкының өлкән яшьтәге гражданнары, инвалидлары, балалары һәм яшьләре, шулай ук башка кимсенә торган төркемнәре статусын хуплау максатында СЮ ККОның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру һәм тәэмин итү;
2. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы СЮ ККОга финанс, мөлкәти, мәгълүмати, консультатив ярдәм күрсәтү;
3. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә актуаль социаль проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән СЮ ККОның проектларын, инновацион социаль хезмәтләрен гамәлгә ашыруга ярдәм;
4. Районның иҗтимагый тормышында актив катнашучы гражданнар саны артыруга ярдәм итү;
5. Үсеп килүче буынга хәрби-патриотик тәрбия бирү.
6. Милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр өлкәсендә иҗтимагый инициативаларга ярдәм итү.
7. Социаль эшкуарлыкны үстерү.

Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары:
Программа 2019-2020 елларда гамәлгә ашырыла.

Программаның төп чараларына характеристика
Программа чаралары исемлеге әлеге Программага 1 нче кушымтада китерелгән.

**Программа индикаторлары**

| **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге** | **Индикатор күрсәткечләре** | |
|---|---|---|
| | **2019 ел** | **2020 ел** |
| Ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар саны, берәмлекләр | 6 | 8 |
| Зеленодольск муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар саны, берәмлекләр | 8 | 10 |
| Зеленодольск муниципаль районында уздырылган иҗтимагый акцияләр һәм чаралар, берәмлекләр саны | 7 | 11 |

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 5000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән республика бюджеты акчалары - 2000 мең сум, муниципаль бюджет акчалары - 0 мең сум, бюджеттан тыш чаралар - 3000 мең сум.

| Финанслау чыганаклары | 2019 ел | 2020 ел | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| Республика бюджеты | 1000 | 1000 | 2000 |
| Муниципаль бюджет | - | - | - |
| Бюджеттан тыш чыганаклар | 1500 | 1500 | 3000 |
| Программа буенча барлыгы | 2500 | 2500 | 5000 |

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс чорына муниципаль бюджет формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында муниципаль заказчы - координатор төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны гамәлгә ашыруның барышын һәм акчаларны турыдан-туры башкаручылар тарафыннан нәтиҗәле файдалануны котрольдә тота. Программа чараларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив актлары нигезендә катгый рәвештә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль заказчы - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты.

Программаның координаторы һәм гомуми контроль - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Программада катнашучылар - Зеленодольск муниципаль районы территориясендә теркәлгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар.

Программаны ярдәмче башкаручылар:

- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесе;

-Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;

-Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган Зеленодольск муниципаль районы оешмалары (алга таба - ЗМР СЮ ККО);

- Массакүләм мәгълүмат чаралары.

Программа буенча ярдәмче башкаручылар билгеләнгән вакытта (I квартал, I яртыеллык һәм 9 ай йомгаклары буенча - хисап чорыннан соң килүче айның 15 санына кадәр; ел йомгаклары буенча - хисап чорыннан соң килүче 1 февральгә кадәр; ел йомгаклары буенча - 1 февральгә кадәр, киләсе хисап чорыннан соң) Программаның үтәлеше турында мәгълүмат әзерлиләр.

Программа кысаларында СЮ ККОга ярдәм түбәндәге формаларда күрсәтелә:

- финанс формасы;

мөлкәти форма;

-мәгълүмати һәм консультация ярдәме.

Районда эшкуарлык эшчәнлеген алып бармый торган коммерциягә карамаган оешмаларга милек ярдәме Зеленодольск муниципаль районының «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ белән килештерелгән озак сроклы (офис урнаштыру өчен) яки кыска сроклы (аерым чаралар үткәрү өчен) нигездә, шул исәптән түләүсез яки ташламалы аренда ставкалары буенча торак булмаган биналарны файдалануга тапшыру юлы белән башкарыла ала.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертү, СЮ ККО һәм җәмәгатьчелек вәкилләре белән аңлату эшләре алып бару, ММЧда һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмати материаллар урнаштыру мәсьәләләре буенча СЮ ККО консультация ярдәме күрсәтелә.

## V. Программаның икътисади һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ел саен Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советында Программа чараларын гамәлгә ашыру йомгаклары буенча Программа Координаторы (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты) докладын тыңларга.

«2019-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасына кушымта

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләүнең индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Чараларның атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләр индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | Финанслау чыганагын күрсәтеп беркетү, мең сум. | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Максат исеме: Коммерциягә карамаган оешмаларның социаль юнәлешле эшчәнлеген һәм аларның Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешендә катнашуын стимуллаштыру, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ татулыкны саклап калу, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген һәм халыкка күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын арттыру, дәүләт һәм җәмгать мәнфәгатьләренең балансылыгы нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү. | | | | | | | | |
| Бурыч исеме: 1.Коммерциягә карамаган оешмаларга һәм социаль юнәлешле эшмәкәрләргә мөлкәти, финанс, мәгълүмати һәм консультатив ярдәм күрсәтү механизмнарын үстерү. | | | | | | | | |
| 1. | СЮ ККО мөлкәти ярдәм күрсәтү | «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ | 2019-2020 | СЮ ККО саны | 2 | 2 | - | - |
| 2. | Торак өлкәсендә халыкны иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп итү өлешендә СЮ ККО үстерү | «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ | 2019-2020 | СЮ ККО саны | 2 | 2 | - | - |
| 3. | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә теркәлгән СЮ ККО реестрын алып бару | ЗМР БК | 2019-2020 | СЮ ККО саны | - | - | - | - |
| 4. | Социаль эшкуарлыкка | «Зеленый Дол» инвестиция | 2019-2020 | Семинарлар | 2 | 3 | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ярдәм мәсьәләләре буенча уку-укыту семинарлары оештыру | үзәге» АУ | | саны | | | | |
| 5. | ККО һәм социаль юнәлешле эшкуарларның федераль һәм төбәк программаларында катнашу өчен конкурс документациясен әзерләүдә ярдәме | «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» АУ | 2019-2020 | Гариза бирүчеләр саны | 3 | 5 | - | - |
| Бурыч исеме: 2.Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында популярлаштыру. | | | | | | | | |
| 6. | СЮ ККО эшчәнлеге турында мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру | ЗМР Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге (килешү буенча) | 2019-2020 | Мәкаләләр саны | 3 | 4 | - | - |
| 7. | СЮ ККОның Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре белән уртак эш очрашуларын оештыру һәм уздыру | ЗМР БК | 2019-2020 | Очрашулар саны | 4 | 4 | - | - |
| 8. | СЮ ККОның мәгълүмати, муниципаль щитларда үткәрелә торган чаралары турында мәгълүмат урнаштыру | ЗМР БК кулланучылар базары бүлеге | 2019-2020 | Баннерлар саны | 3 | 3 | - | - |
| Бурыч исеме: 3. Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга өстәмә белем бирүне үстерү буенча шәһәр чаралары уздыруда, сәламәт яшәү рәвешен һәм массакүләм спортны популярлаштыруда, балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүдә ярдәм күрсәтү | | | | | | | | |
| 9. | Физкультура-савыктыру һәм спорт юнәлешендәге СЮ ККОга консультатив һәм оештыру ярдәме | ЗМР БК Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе | 2019-2020 | Мөрәҗәгатьләр саны | 15 | 18 | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтү | | | | | | | |
| Бурыч исеме: 4. Гражданнарның социаль куркыныч рәвешләрен профилактикалауга, авыр тормыш хәлендә калган затларны социаль тернәкләндерүгә юнәлдерелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү формаларын камилләштерү. | | | | | | | | |
| 10. | СЮ ККО ягыннан халыкның кимсенә торган төркемнәренә (наркотиклар кулланучыларга, мигрантларга һ.б.) социаль-психологик һәм медицина хезмәтләре күрсәтү. | ЗМР БК СЮ ККО | 2019-2020 | Күрсәтелгән хезмәтләр саны | 39 | 45 | - | - |
| 11. | Бәйлелектәге гражданнар өчен социаль-психологик хезмәтләр күрсәткәндә СЮ ККОга мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү | ЗМР БК | 2019-2020 | Кеше саны | 10 | 15 | - | - |